А. S. S. Ç. Qazan LENIN isem.
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань
Уг. К. № 27

ПӘНҖЕШӘМБЕ
14 МАРТ
1940 ел
№ 61 (5861)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлеге 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия тормышы һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—73, культура бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төште редакция 3—73, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

СССР БЕЛӘН ФИНЛЯНДИЯ РЕСПУБЛИКАСЫ АРАСЫНДА СОЛЫХ ДОГОВОРЫ

Кичә Москвада СССР белән Финляндия Республикасы арасында солых договорына кул куелды. Бүген 12 сәгаттә сугыш хәрәкәтләре туктатыла. Совет Хөкүмәтенең үзенең алдына куйган бурычлары хәл ителде. Дәүләтебезнең төньяк-көнбатыш чикләренә куркынычсызлык, бигрәк тә бөтен дөньяда иң зур эшчеләр үзәге булган Ленинградка куркынычсызлык тулысынча тәэмин ителде. Совет тынычлык политикасының яңа тантанасын бөтен совет халкы гына түгел, бәлки бөтен дөньядагы хезмәт ияләре дә зур канәгатьләнү белән каршы алырлар.

СССР белән Финляндия Республикасы арасындагы договор үзара ныклы тыныч мөнәсәбәтләр тудыра. Аларның төп шарты—үзара куркынычсызлык тәэмин итү, шул исәптән Ленинград һәм Мурманск шәһәрләренә, шулай ук Мурманск тимер юлына куркынычсызлык тәэмин итү. Выборг (Випури) шәһәре һәм Выборг заливы белән берлектә бөтен Карелия бугазы, Кексгольм, Сортавала, Суоярви шәһәрләре белән берлектә Ладога күленең көнбатыш һәм төньяк яры, Фин заливындагы күп кенә атаулар, Меркярвидән көнчыгыштарак булган территория һәм Куолаярви шәһәре, Рыбачий һәм Средний ярым атауларының бер өлеше СССР территориясе составына кушыла.

СССР Фин заливына керү юлын агрессиядән саклый алырлык хәрби диңгез базасы төзү өчен Ханко ярым атавын һәм аның тирәсендәге атауларны 30 елга арендага ала. 1920 нче елгы договорда күрсәтелгәнчә, Финляндия үзенең төньяк ярында хәрби портлар ясамаска һәм бу суларда вак суднолардан башка сугыш суднолары тотмаска сүз бирә.

СССР Петсамо өлкәсе аркылы Норвегиягә һәм Норвегиядән транзит хокукы, шулай ук СССР белән Швеция арасында товар йөртү хокукы ала.

СССР һәм Финляндия Килешүче Якларның берсенә каршы юнәлдерелгән берниндә дә союзлар төземәскә һәм коалицияләрдә катнашмаска сүз бирәләр.

Солых договорының төп шартлары шулар. Алар 1939 нчы елның 29 нчы ноябрендә Совет Хөкүмәте башлыгы иптәш В. М. Молотовның радио буенча сөйләгән речендә ясаган белдерүенә тулысынча туры киләләр:

„Безнең чараларның бердән-бер максаты—Советлар Союзының һәм бигрәк тә өч миллион ярым халкы булган Ленинградның куркынычсызлыгын тәэмин итү".

Үзенең тынычлык политикасы бурычларына турылыклы булган Совет Хөкүмәте башка дәүләтләрнең бәйсезлегенә бер кайчан да һөҗүм итмәде. Финляндия белән Советлар Союзы арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең бөтен тарихы моны ачык күрсәтә. 1917 нче елның 31 нче декабрендә Совет Хөкүмәте Финляндиянең дәүләт бәйсезлеген таныды. Шул вакыттан бирле Совет Дәүләте үзенең күршесе белән договор мөнәсәбәтләрен саклап килде, ләкин Финляндиянең хакимлек итүче даирәләре Советлар Союзы белән яхшы күршелек мөнәсәбәтләре саклау турында кайгыртмадылар, алар Ленинград янында сугыш өчен плацдарм хәзерләделәр.

Башланып киткән икенче империалистик сугыш дәүләт чикләрен ныгыту буенча Совет Хөкүмәте алдына бурыч куйды. Бу—империалистик сугыш шартларында [illegible] Финляндия хөкүмәтенә [illegible] тәкъдим итте.

СССР Финляндия хөкүмәтенә дә һәр ике дәүләт өчен бер үк дәрәҗәдә файда китерерлек, аларның суверенитет хокукларына кагылмаслык һәм Совет дәүләтенең төньяк-көнбатыш чикләренә, аерым алганда Ленинградка куркынычсызлык бирә торган чараларны тәкъдим итте. Безнең Совет Хөкүмәтенең тынычлык политикасы турында иптәш М. И. Калинин болай дигән иде:

„Европада тынычлык белән кызыксынмаучы даирәләр тарафыннан таратыла торган магнәсез хәбәрләргә дә карамастан, бу сөйләшүләрнең бердән-бер максаты Советлар Союзы белән Финляндия арасында үзара мөнәсәбәтләрне ныгытудан, Советлар Союзына һәм Финляндиягә куркынычсызлыкны тәэмин итү эшендә һәр ике илнең дусларча бергәләшеп эшләүләрен ныгытудан гыйбарәт".

Маглүм ки, 1939 нчы елның октябрь—ноябрь айларында булган бу сөйләшүләр Советлар Союзыннан булмаган сәбәпләр буенча ахрынача илтеп җиткерелмәделәр. Ул чагында сөйләшүләрнең уңышлы баруына Европадагы кайбер дәүләтләрнең җитәкче даирәләренең йогынтысы комачаулады, алар Европаның көнчыгышында озакка сузылган ныклы тынычлык урнаштыру белән аз гына да кызыксынмадылар, киресенчә, Европаның бу почмагында сугыш уты кабызу һәм утны Советлар Союзына каршы юнәлдерү өчен бөтен көчләрен бирделәр.

Англия—Франциянең империалистик даирәләре, моннан элек Польшаны һәм башка дәүләтләрне котырткан кебек, Финляндияне Советлар Союзына каршы сугышка котырттылар, бу сугышта „гарантияләр" һәм булышлык вәгдә иттеләр, Англия—Франция ярдәме белән төзелгән ныгытмалар Кызыл Армия алырлык түгел дигән хыяллар тараттылар.

Өч ай дәвам иткән сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә бу хыялларның эзе дә калмады. Бөтен дөньяның җәмагатьчелек фикерен буташтырырга маташу теләге белән Англиянең һәм Франциянең сатлык матбугаты тарафыннан Советка каршы таратылган кабахәт яла ягулар һәм ялганнар белән берлектә алар юкка чыктылар.

Батыр Кызыл Армия Карелия бугазында Англия—Франция техникасы тарафыннан бик нык дип игълан ителгән ныгытмаларны җимерде. Кызыл Армиянең һәм Кызыл Диңгез Флотының сугышчылары, командирлары һәм политработниклары, патриотлык ялкыны белән рухланып, большевикларга алынмаслык крепостьлар юклыгын, Кызыл Армия Советлар Союзының шанлы сакчысы һәм безнең Ватанның дошманнары өчен дәһшәтле кылыч икәнлеген күрсәттеләр.

Англия—Франция империалистлары тарафыннан Европада сугыш уты кабызу планнары да җимерелде. Милләтләр Лигасындагы шау-шулы чыгышлар да, янаулар да, сатып алулар да ярдәм итмәде.

Кайбер дәүләтләр вәгдә иткән ярдәм итмәде. Империалистик матбугат Советлар Союзына каршы көрәшкә доброволецлар чакырып юкка гына кычкырды. Миллионнарча хезмәт ияләренең теләктәшлеге Советлар ягында булды. Халыкара сугыш провокаторларының Финляндия халкы турында түгел, бәлки сугышны дәвам иттерү турында гына кайгыртканлыклары ачык күренде.

Ерткыч ачу белән сукыраймаган һәм ялганчы буржуаз матбугат язганга алданмаган һәрбер кеше бик җиңел генә алдан күрә алган хәл килеп чыкты. Сугыш уты кабызучыларның тырышлыкларына да карамастан, Советлар Союзы үзенең чикләренә куркынычсызлыкны тәэмин итте, һәм моны ул Финляндиянең бәйсезлегенә кагылмыйча эшләде. Совет Хөкүмәте тынычлык политикасына турылыклы. Хәзер Финляндия белән төзелгән солых договоры моны тагын бер тапкыр күрсәтә. Бу солых договоры белән Советлар Союзының куркынычсызлыгын тәэмин итү бурычы хәл ителде. Менә шуңа күрә дә Карелия бугазы һәм Ладога күленең төньяк ярлары Советлар Союзына бирелә. Фин заливына керү юлын агрессиядән саклый алырлык СССР хәрби-диңгез базасы төзү өчен Ханко ярым атавын Советлар Союзына 30 елга арендага бирү тулы рәвештә мөмкин булды.

Совет халкы үзенең теләгәненә ирешкән. Моның өчен ул үзенең геройк Кызыл Армиясенә, аның батырлыкларына бурычлы. Моның өчен ул үз хөкүмәтенә, үзенең большевиклар партиясенә һәм аның тынычлык политикасына бурычлы, бу хөкүмәт бер кайчан да совет халкының интересларына зиан китермәс һәм Советлар иленә тынычлыкны, куркынычсызлыкны һәм тыныч яшәүне тәэмин итү өчен үз теләген үткәрер.

Советлар Союзы чикләрендә тынычлык җиңде. Бу—Сталинчыл тынычлык политикасының яңа бөек җиңүе. Җинаятьле империалистик сугышны туктату белән кызыксынучы бөтен алдынгы кешелек дөньясы аны шатланып котлый. Яла ягучылар үзләренең көчсезлекләрен сизеп, тынарга тиешләр. Сугыш уты кабызучылар бик нык җиңелделәр. Алар Советлар Союзына каршы уйлаган походларында үзләренең иң әһәмиятле базаларыннан берсен югалттылар. Советлар Союзы тынычлык сакчысы булып, хезмәт ияләренең таянычы һәм ышанычы булып, какшамыйча тора.

„Правда" 13 нче март.

Советлар Союзы белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турында

7—12 нче мартта Москвада бер яктан СССР уполномоченныйлары—СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш В. М. Молотов, СССР Верховный Советы Президиумы члены иптәш А. А. Жданов һәм комбриг иптәш А. М. Василевский, икенче яктан—Финляндия Республикасы уполномоченныйлары—Финляндиянең Министрләр Советы Председателе Р. Рюти әфәнде, министр Ю. К. Паасикиви, генерал К. Р. Вальден һәм профессор В. Войонмаа арасында,—СССР белән Финляндия арасындагы сугыш хәрәкәтләрен туктату һәм килешү договоры төзү турындагы мәсьәлә буенча сөйләшүләр барды.

Сөйләшүләр 1940 нчы елның 12 нче мартында Советлар Союзы белән Финляндия арасында солых договорына кул кую белән тәмам булды.

Солых договорының һәм аңа кушымта ителгән протоколның текстлары түбәндә китереләләр.

Совет Социалистик Республикалар Союзы белән Финляндия Республикасы арасында солых договоры

Бер яктан, СССР Верховный Советы Президиумы һәм
икенче яктан Финляндия Республикасы Президенты
ике ил арасында килеп чыккан сугыш хәрәкәтләрен туктату һәм үзара ныклы тыныч мөнәсәбәтләр булдыру теләге белән кулланып
үзара куркынычсызлык тәэмин итүнең, шул исәптән Ленинград һәм Мурманск шәһәрләренә, шулай ук Мурманск тимер юлына куркынычсызлык тәэмин итүнең төгәл шартларын билгеләү Килешүче Якларның икесенең дә интересларына туры килүгә ышанган хәлдә
шушы теләк белән Солых договоры төзергә кирәк дип таптылар һәм үзләренең уполномоченныйлары итеп
СССР Верховный Советы Президиумы:
СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары Вячеслав Михайлович Молотовны,
СССР Верховный Советы Президиумы члены Андрей Александрович Ждановны,
комбриг Александр Михайлович Василевскийны,
Финляндия Республикасы Президенты:
Финляндия Республикасының Министрләр Советы Председателе Ристо Рютины,
министр Юхо Кусти Паасикивины,
генерал Карл Рудольф Вальденны,
профессор Вяйнэ Войонмааны билгеләделәр.
Югарыда күрсәтелгән уполномоченныйлар, тиешле формада төзелгән һәм тулы тәртиптә дип табылган полномочиеләрен үзара күрсәткәннән соң, түбәндәгеләр турында килештеләр:

Статья I.

СССР белән Финляндия арасындагы сугыш хәрәкәтләре шушы договорга кушымта ителгән протоколда әйтелгән тәртиптә хәзер үк туктатылалар.

Статья II.

СССР белән Финляндия Республикасы арасында дәүләт чиге яңа линия буенча билгеләнә. Бу линия буенча Выборг (Випури) шәһәре, Выборг заливы һәм андагы атаулар белән берлектә бөтен Карелия бугазы, Ладога күленең көнбатыш һәм төньяк яры һәм андагы Кексгольм, Сортавала, Суоярви шәһәрләре, Фин заливындагы күп кенә атаулар, Меркярвидән көнчыгыштарак булган территория һәм андагы Куолаярви шәһәре, Рыбачий һәм Средний ярым атауларының бер өлеше шушы договорга кушымта ителгән карта буенча СССР территориясе составына кушыла.

Чик линиясен тулырак итеп язуны Килешүче Якларның вәкилләреннән төзеләчәк катнаш комиссия билгеләячәк. Бу комиссия шушы договорга кул куелган көннән 10 көн срок эчендә төзелергә тиеш.

Статья III.

Килешүче Яклар икесе дә бер-беренә һәр төрле һөҗүмнән тыелырга һәм Килешүче Якларның берсенә каршы юнәлдерелгән нинди булса да союзлар төземәскә яки коалицияләрдә катнашмаска сүз бирәләр.

Статья IV.

Финляндия Республикасы, Советлар Союзы тарафыннан ел саен 8 миллион фин маркасы күләмендә түләү шарты белән, Ханко ярым атавын һәм аның тирәсендә көньякка һәм көнчыгышка таба 5 миль һәм анардан көнбатышка һәм төньякка таба 3 миль ераклыктагы диңгез территориясен һәм аның тирәсендәге күп кенә атауларны, анда Фин заливына керү юлын агрессиядән саклый алырлык хәрби-диңгез базасы төзү өчен, шушына кушымта ителгән картага туры китереп, 30 ел срок белән Советлар Союзына арендага бирергә ризалык белдерә, шуның белән бергә диңгез базасын саклау теләге белән анда Советлар Союзына аның үз исәбенә кирәк кадәр санда коралланган җир өсте һәм һава көчләре тоту хокукы бирелә.

Шушы договор гамәлгә керү моментыннан 10 көн эчендә Финляндия хөкүмәте Ханко ярым атавыннан үзенең барлык гаскәрләрен чыгара һәм Ханко ярым атавы, аның тирәсендәге барлык атаулар белән берлектә, договорның шушы статьясе буенча, СССР карамагына күчә.

Статья V.

1920 нче елгы килешү договоры буенча Совет дәүләте тарафыннан Финляндиягә ирекле рәвештә бирелгән Петсамо өлкәсеннән СССР үзенең гаскәрләрен чыгарырга сүз бирә.

1920 нче елгы килешү договорында әйтелгәнчә, Финляндия Төньяк Боз океанының үз ярлары буендагы суларда, 100 тоннадан кимрәк күләмдәге кораллы суднолардан тыш (боларны Финляндия теләгән кадәр санда тота ала), сугыш суднолары һәм башка төрле кораллы суднолар тотмаска, шулай ук һәр кайсының авырлыгы 400 тоннадан артык булмаган, 15 тән артык сугыш судносы һәм башка төрле кораллы суднолар тотмаска сүз бирә.

Шул ук договорда күрсәтелгәнчә, Финляндия югарыда әйтелгән суларда су асты көймәләре һәм коралландырылган һава караблары тотмаска сүз бирә.

Шулай ук Финляндия, шул ук договорда әйтелгәнчә, бу яр буенда сугыш флоты өчен хәрби портлар һәм базалар ясамаска һәм югарыда әйтелгән суднолар өчен һәм аларны коралландыру өчен кирәк булганнан артык күләмдә хәрби ремонт мастерскойлары төземәскә сүз бирә.

Статья VI.

1920 нче елгы договорда күрсәтелгәнчә, Советлар Союзына һәм аның гражданнарына Петсамо өлкәсе аркылы Норвегиягә тоткарсыз бару һәм кайту хокукы бирелә, шуның белән бергә Петсамо өлкәсендә Советлар Союзына консуллык оештыру хокукы бирелә.

Петсамо өлкәсе аркылы СССР дан Норвегиягә ташыла торган йөкләр, шулай ук шул ук өлкә аркылы Норвегиядән СССР га ташыла торган йөкләр, транзитны тәртипкә салу өчен кирәк булган контрольдән тыш, караудан һәм контрольдән азат ителәләр, шулай ук алардан таможня пошлиналары, транзит җыемнары һәм башка төрле җыемнар алынмый.

Транзит йөкләренә югарыда әйтелгән контроль бары тик халыкара хәбәрләшүдәге гадәтләр буенча билгеләнгән хәлләрдә саклана торган формада гына ясала.

Петсамо өлкәсе аркылы Норвегиягә һәм Норвегиядән кире СССР га кайтучы СССР гражданнарына тиешле Совет органнары тарафыннан бирелә торган паспортлар нигезендә тоткарсыз үтеп йөрү хокукы бирелә.

Гамәлдәге гомуми положениеләрне саклаганда Советның коралланмаган очу аппаратларына Петсамо өлкәсе аркылы СССР белән Норвегия арасында очарга хокук бирелә.

Статья VII.

Финляндия хөкүмәте Советлар Союзына СССР белән Швеция арасында товарлар йөртү хокукы бирә һәм иң кыска тимер юл буенча бу транзитны үстерү теләге белән, СССР һәм Финляндия Кандалакша шәһәрен Кемиярви шәһәре белән тоташтыру өчен һәр ике як үз территориясендә, мөмкин кадәр 1940 нчы ел эчендә тимер юл төзергә кирәк дип табалар.

Статья VIII.

Шушы договор гамәлгә кергәннән соң, Килешүче Яклар арасында экономик мөнәсәбәтләр яңартыла һәм Килешүче Яклар шушы теләк белән сәүдә договоры төзү өчен сөйләшүләр башлаячаклар.

Статья IX.

Бу солых договоры кул куелгач та гамәлгә керә һәм соңыннан ратификацияләнергә тиеш.

Ратификация актларын алмашу 10 көн срок эчендә Москва шәһәрендә булачак.

Бу договор ике оригиналда итеп, һәркайсы рус, фин һәм швед телләрендә, Москва шәһәрендә, 1940 нчы елның 12 нче мартында төзелде.

В. МОЛОТОВ.
А. ЖДАНОВ.
А. ВАСИЛЕВСКИЙ.

РИСТО РЮТИ.
Ю. ПААСИКИВИ.
Р. ВАЛЬДЕН.
ВЯЙНЭ ВОЙОНМАА.

СССР белән Финляндия арасында 1940 нчы елның 12 нче мартында төзелгән солых договорына протокол

Килешүче Яклар сугыш хәрәкәтләрен туктату һәм гаскәрләрне договор буенча билгеләнгән дәүләт чигенә алып китү өчен түбәндәге тәртипне билгелиләр:

1. Сугыш хәрәкәтләре ике яктан да 1940 нчы елның 13 нче мартында Ленинград вакты белән 12 сәгаттә туктатыла.

2. Сугыш хәрәкәтләрен туктату өчен билгеләнгән сәгаттән алып, алгы частьләр урнашкан урыннар арасында бер километр киңлектә нейтраль полоса билгеләнә, шуның белән бергә, беренче көн эчендә, яңа дәүләт чиге буенча икенче як территориясендә булган якның хәрби часте бер километрга алып кителә.

3. Гаскәрләрне яңа дәүләт чигенә алып китү һәм икенче як гаскәрләрен бу чиккә якынайту Фин заливыннан Лиексага кадәр булган бөтен чик буенда 1940 нчы елның 15 нче мартында 10 сәгаттән һәм Лиексадан төньяктарак 16 нчы мартта 10 сәгаттән башлана. Гаскәрләрне алып китү көн саен тәүлегенә кимендә 7 километр чигенү юлы белән үткәрелә, шуның белән бергә икенче як гаскәрләренең алга үтүләре чигендерелүче гаскәрләрнең тыл частьләре белән икенче як гаскәрләренең яңа чиккә китерелә торган алгы частьләренең арасы кимендә 7 километр булырлык итеп алып барыла.

4. 3 нче пунктка туры китереп, дәүләт чигенең аерым участкыларында гаскәрләрне алып китү сроклары түбәндәгечә билгеләнә:

а) Тунца-Йоки елгасы тамагыннан алып, Куолаярви, Такала, Иоукамо-Ярви күленең көнчыгыш яры участкыларында ике якның да гаскәрләрен алып китү 1940 нчы елның 20 нче мартында 20 сәгаткә тәмам була;

б) Латва районында Кухмониемидән көньякка таба булган участкыда гаскәрләрне алып китү 1940 нчы елның 22 нче мартында 20 сәгаткә тәмам була;

в) Лонгаваара, Вяртсила, Маткаселька станциясе участкысында ике якның гаскәрләрен алып китү 1940 нчы елның 26 нчы мартында 20 сәгаткә тәмам була;

г) Маткаселька станциясе, Койцанлахти участкысында гаскәрләрне алып китү 1940 нчы елның 22 нче мартында, 20 сәгаткә тәмам була;

д) Койцанлахти, Энсо станциясе участкысында гаскәрләрне алып китү 1940 нчы елның 25 нче мартында 20 сәгаткә тәмам була;

е) Энсо станциясе, Бата атавы участкысында гаскәрләрне алып китү 1940 нчы елның 19 нчы мартында 20 сәгаткә тәмам була.

5. Петсамо районыннан Кызыл Армия гаскәрләрен эвакуацияләүне 1940 нчы елның 10 нчы апреленә тәмам итәргә.

6. Ике якның командованиесе гаскәрләрне дәүләт чигенә алып киткәндә икенче якка күчә торган шәһәрләрдә һәм урыннарда аларны төзек хәлдә калдыру өчен кирәкле чараларны күрергә һәм шәһәрләрне, местечколарны, оборона һәм хуҗалык корылмаларын (күперләрне, плотиналарны, аэродромнарны, казармаларны, складларны, тимер юл узелларын, промышленность предприятиеләрен, телеграфны, электростанцияләрне) бозылудан һәм юкка чыгудан саклау өчен тиешле чараларны күрергә сүз бирәләр.

7. Шушы протоколның 6 нчы пунктында күрсәтелгән районнарны, пунктларны, шәһәрләрне һәм башка объектларны бер яктан икенче якка тапшырган вакытта килеп чыгуы мөмкин булган барлык мәсьәләләр ике як вәкилләре тарафыннан урында хәл ителәләр, моның өчен ике армиянең дә үтә торган һәрбер төп юлында командование тарафыннан махсус уполномоченныйлар билгеләнә.

8. Гаскәри пленныйларны алмашу сугыш хәрәкәтләре туктатылганнан соң мөмкин кадәр кыска срок эчендә, махсус килешү нигезендә үткәрелә.

В. МОЛОТОВ.
А. ЖДАНОВ.
А. ВАСИЛЕВСКИЙ.

РИСТО РЮТИ.
Ю. ПААСИКИВИ.
Р. ВАЛЬДЕН.
ВЯЙНЭ ВОЙОНМАА.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ҺӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Революцион уяулыкны тагын да күтәрик

Татарстан АССР ның эчке эшләр халык комиссары иптәш Морозов речендән

Иптәш Сталин безнең партиябезне, бөтен совет халкын һәр вакытта да уяу булырга, эшче сыйнфының дошманнарына карата рәхимсез булырга өйрәтә. Иптәш Сталинның күрсәтмәләрен хәтердә нык тоткан хәлдә, безнең социалистик разведкабызны ныгытырга, халык дошманнарын тамырларыннан йолкып ташлауга разведкабызга системалы булышырга кирәк.

Безнең кадрларыбызның барсында да революцион уяулык тиешле югарылыкта тора дип әйтеп буламы? Юк, моны әйтеп булмый әле. Политик яктан сукыр булып әверелгән аерым коммунистлар бар. Советка каршы элементлар тарафыннан таратыла торган кулакчыл, дошман настроениеләрне алар күрми үтәләр, мондый фактлар әле байтак. Мәсәлән, Казан заводларының берсендә җаваплы работник, үзе янында эшләүче кешеләр тарафыннан үткәрелгән дошманчыл хәрәкәтләрне озак вакытлар буенча күрә алмаган. Ул гына да түгел, партия члены булган бу кеше аларга уңай отзывлар биргән.

Икенче мисаль. Сарман районы авылларының берсендә, кулак һәм мулла малайлары авыл советында һәм колхозда җитәкче постларга үрмәләп, озак вакытлар буена җимерү эше алып барганнар, каралтыларга ут төрткәннәр, хәйваннарны агулаганнар, колхозда учет һәм отчет эшләрен бутаганнар. Дошманнарның җимерү эшләре турында район оешмаларына сигналлар булган, билгеле, ләкин алар һичбер чара күрмәгәннәр. Революцион уяулыкның тупаслану һәм дошман калдыкларына каршы көрәшне йомшарту фактлары югары уку йортларында да урын алган.

Болар барсы да шуны күрсәтәләр ки, революцион уяулык көн тәртибеннән бер вакытта да төшәргә тиеш түгел. Революцион уяулык большевикның аерылмаслык сыйфаты икәнлеген хәтердә нык тотарга кирәк.

Тукталырга тиешле булган икенче мәсьәлә—бу, авыл хуҗалыгы турында. Республикабыз авыл хуҗалыгының җидди рәвештә артка калуының сәбәбе нәрсәдә соң? Ул, барыннан да элек, ВКП(б) Өлкә Комитетының җитәкчелек практикасында. Партиянең Өлкә Комитеты, аеруча аның авыл хуҗалыгы бүлеге һәм авыл хуҗалыгы мәсьәләләре буенча Өлкә Комитетының секретаре иптәш Матвеев политик бурычларны хуҗалык бурычлары белән бергә бәйли алып бармаганнар.

Татарстан Совнаркомы һәм Наркомземы да колхозларга һәм МТС ларга кирәгенчә җитәкчелек итмәгәннәр. Еш кына шундый хәл була иде: Өлкә Комитеты бюросында авыл хуҗалыгы мәсьәләсе куелса, Совнарком җитәкчеләре районнарда һәм колхозларда эшнең торышы турында бюрога бер нәрсә дә әйтә алмыйлар иде. Ул чакта, эшне җентекләбрәк тикшерү өчен комиссия төзелә,—шуннан соң гына карар чыгарыла иде.

Татарстан Наркомземы СССР Наркомземы алдында күз буяу белән шөгыльләнгән, урып-җыю эшләре төгәлләнде, дип СССР Наркомземына дөрес булмаган хәбәрләр биргән. Гамәлдә исә уңышның бер өлеше җыелмыйча калган һәм әле дә кар астында ята. Совнарком җитәкчеләре бу фактка әһәмият биреп карамадылар, чара күрмәделәр һәм Өлкә Комитеты нарком иптәш Черзорга шелтә биргәннән соң гына сөйләнә башладылар.

Республикабызның җидди рәвештә артка калуының тагын бер сәбәбе бар. Ул, үз карарларыбызның үтәлешен тикшереп бармаудан гыйбарәт. Үтәлешне тикшерү эше системалы булырга тиеш, партия, совет һәм хуҗалык оешмаларының барлык тармакларында үтәлешне тикшерүнең башында икенче дәрәҗәдәге кешеләр түгел, ә җитәрлек дәрәҗәдә авторитетлары булган кешеләр—оешма җитәкчеләре үзләре торырга тиеш икәнлеге турында иптәш Сталинның күрсәтмәләрен ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм аның авыл хуҗалыгы бүлеге үтәп җиткермәгән.

ВКП(б) Өлкә Комитетының яңа сайланган составы Татарстан республикасын алдынгы республикалар, крайлар һәм өлкәләр сафына чыгаруга ирешергә тиеш.

Матбугатка җитәкчелекне көчәйтергә

„Азат Хатын“ журналы редакторы иптәш Ахметшина речендән

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыру буенча Өлкә Комитетының зур уңышлары бар. Ләкин шуның белән бергә Өлкә Комитетының эшендә күп кенә җитешсезлекләр дә яшәп килә әле. Мин Өлкә Комитетының матбугатка, бигрәк тә, журналларга ничек җитәкчелек итүенә тукталам. Дөресен әйтергә кирәк: Өлкә Комитеты журналларга тиешенчә игтибар итми. Минем ничек эшләвем турында, хәтта телефон аша да сорашучы булмады. Минем, журналга ник җитәкчелек итмисез, дип соравыма, пропаганда һәм агитация бүлегенең матбугат секторы инструкторы иптәш Рәхмәтуллин:

— Сезнең журналда хаталар җибәрелми, сезгә аерым игтибар итүнең кирәге юк, дип җавап бирде. Мәсьәләне болай итеп кую бөтенләй дөрес түгел. Чөнки Өлкә Комитеты җитәкчелек итсә, без тагы да яхшырак эшләр идек.

Икенче мәсьәлә—„Красная Татария“ һәм „Кызыл Татарстан“ издательствосының эше турында. Нигә мин бу мәсьәләгә игтибар бирәм? Чөнки издательствоның эшенә редакцияләрнең шактый эше бәйләнгән. Бу издательство өлкәдә чыга торган 6 газета һәм 4 журнал редакцияләрен берләштерә. Ләкин издательствоның эше һич тә канәгатьләнерлек түгел. Директор иптәш Злобин бүгенге

көнгә кадәр үзенең бурычларын аңламый. Ул акча эшләре белән җитәкчелек итүне генә үз бурычы итеп карый. Александров исемендәге типографиянең эшчеләре һәм хезмәткәрләре арасында тәрбия эше, социалистик ярыш бик начар куелган. Типографиядәге 194 эшчедән 4 кенә кешенең ярыш договоры бар. График системалы рәвештә бозыла, эштә брак күп. Злобин үзенең эшли белмәве нәтиҗәсендә редакция работниклары арасында авторитетын югалткан. А. П. Чеховның „Футлярдагы кеше“ дигән хикәясен беләсездер. Ул хикәядәге геройларның берсе Беликов кебек, иптәш Злобин да үзен страховать итәргә ярата. Ул бер генә мәсьәләне дә конкрет рәвештә хәл итми, һәр вакыт „ул-бу булмагае“ дип шикләнә һәм мәсьәләне мөмкин кадәр хәл итмичә калдырырга тырыша.

Өлкә Комитетының яңа составы менә болардан тиешле нәтиҗәне ясар, издательствоның эшен яхшырту буенча кирәкле чараларны күрер дип уйлыйм.

Кадрларны тәрбияләү җидди бурыч

ВКП(б) ның Теләче райкомы секретаре иптәш Бусарев речендән

Партиянең XVIII нче съезды карарлары һәм ВКП(б) уставы нигезендә Өлкә Комитетында һәм район комитетларында яңа бүлекләр төзү партия оешмаларының кадрлар сайлап алудагы эшләрен яхшыртуга зур этәргеч ясады. Бу чорда йөзләрчә яңа кешеләр җитәкче эшләргә күтәрелделәр. Өлкә Комитетының кадрлар бүлеге тарафыннан уздырылган эшләрнең уңышлы нәтиҗәләре турында иптәш Постнова дөрес сөйләде. Ләкин ул, бу эштәге төп кимчелекне—яңа күтәрелгән работникларга кадрлар бүлегенең булышлыгы йомшак икәнлеген күрсәтмәде. Бу мәсьәләдә Өлкә Комитетының оештыру - инструкторлык бүлеге эшендә дә зур кимчелекләр бар.

ВКП(б) Өлкә Комитеты янында инструкторлар өчен периодик рәвештә курслар үткәрүгә, райкомнарның бүлек мөдирләре белән 5—6 көнлек киңәшмә-семинарлар үткәрүгә җитәрлек игтибар бирелмәде. Уңышлы эш тәҗрибәләрен башкаларга күчерү юлы белән дә яңа работникларга зур ярдәм итәргә мөмкин. Ләкин Өлкә Комитеты инструкторлары районнарга барганда бу эшкә игтибар итмиләр. Мәсәлән, совет һәм кооператив оешмалары җитәкчеләре кадрларны ничек тәрбияләүләрен һәм ничек үстерүләрен Теләче райкомының системалы рәвештә тикшереп торуын Өлкә Комитеты инструкторы яхшы башлангыч дип тапты. Ләкин бу уңышлы эш тәҗрибәсе инструкторның блок-нотына язылган килеш калды, башкаларга күчерелмәде.

Аннан соң колхоз председательләре арасында эшләү турында берничә сүз. Бу кешеләргә политик-тәрбия бирү мәсьәләсе белән без начар шөгыльләнәбез. Теге яки бу эш буенча планны ашыгыч үтәргә кирәк булса гына, без алар белән киңәшмәләрне еш үткәрәбез. Дөрес, ВКП(б) Өлкә Комитеты үзенең карарлары һәм күрсәтмәләре белән бу өлкәдә ничек эшләргә кирәклекне күрсәтеп килде. Ләкин, минемчә, бу гына җитми. ВКП(б) ның Москва Өлкә Комитеты периодик рәвештә колхоз председательләрен чакыра, аларның катнашы белән киңәшмәләр уздыра, алар өчен докладлар һәм лекцияләр оештыра, эш тәҗрибәләрен уртаклаша. Бу уңышлы тәҗрибәне партиянең Татарстан оешмасына да күчерергә кирәк. Мондый чараны үткәрү колхозларга гына түгел, бәлки безнең Җир Эшләре Халык Комиссариатына да үзенең эшен яхшыртырга зур ярдәм итәр иде.

Хатын-кызларны җитәкче эшләргә кыюырак күтәрергә

ВКП(б) ның Мамадыш райкомы секретаре иптәш Белоглазов речендән

Партиянең Татарстан оешмасында ВКП(б) сафларын үстерү, кадрлар белән эшләү, партия пропагандасы эшен яхшырту һәм башка тармаклар буенча булган уңышлар партиябезнең, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның көндәлек кайгыртучанлык күрсәтүе һәм җитәкчелеге нәтиҗәсендә яулап алындылар.

Партия сафларын үстерүдә Мамадыш район оешмасы да шактый эшләр башкарды. Отчет чорында партиянең район оешмасы 214 членнан һәм кандидаттан 406 кешегә житте. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң партия сафларын үстерү эше тагын да көчәйде.

Шулай да әле бу эштә җидди кимчелекләр бар. Бердән—райондагы төп профессия эшчеләре һәм работниклары исәбенә үсеш канәгатьләнерлек түгел. Икенчедән—хатын-кызлар арасында эш

тиешенчә җәелдерелмәгән әле. Шуның нәтиҗәсендә, алдынгы хатын-кызлар исәбенә үсеш—13,2 генә процент. Өченчедән—кандидатлык стажлары үткән иптәшләр бар әле. Бу нәрсә алар арасында тиешле тәрбия эше алып бармавыбызны күрсәтә.

Партиянең район оешмасында, бигрәк тә XVIII нче съезддан соң, җидди урын алган мәсьәлә—кадрларны өйрәнү, сайлап алу һәм урнаштыру мәсьәләсе. Без бу эш белән хәзер, моннан бер-ике ел элек булганга караганда, шактый яхшы шөгыльләнә башладык. 1939 нчы елны гына районда җитәкче эшләргә 484 кеше күтәрелде. Аларның 37 проценты хатын-кызлар һәм яртысыннан күбесе партиясезләр.

Кадрлар мәсьәләсендә райкомның һәм Өлкә Комитетының кадрлар бүлекләре күп вакыт работниклар турындагы делоларны тәртипкә китерү эше белән шөгыльләнәләр, производстводагы, колхозлардагы кадрларның эшенә булышлык күрсәтү мәсьәләсенә аз игтибар итәләр. Бу нәрсә Өлкә Комитетының кадрлар бүлегендә нык сизелә. Бу бүлекнең работниклары кадрларны өйрәнү эшен, еш кына, райкомнардан характеристикалар җыю белән чиклиләр. Кай вакыт аерым кешеләргә характеристиканы ай саен сорыйлар, кадрларга практик ярдәм күрсәтү мәсьәләсе белән ныклап кызыксынмыйлар, райкомнарны кадрлар белән эшләргә өйрәтмиләр. Өлкә Комитетының кадрлар бүлегеннән килгән кайбер работниклар, аерым алганда иптәш Хайбуллин, эшкә өйрәтү урынына тупаслыклар күрсәтә. Ул безнең районга 1939 нчы елның август аенда бер көнне кич 9 да килде һәм икенче көнне 12 дә китте. Ул 16 сәгать эчендә 20 кеше белән „беседа“ ясады. Башта кешеләрне берәмләп кенә чакырды, ә аннан соң сәгать 10 да җитәкче работниклардан 10 кешене, шул исәптән 3 секретарьны җыеп алып „беседа“ үткәрергә керешә. Беренче сорауны ул, райуполкомзаг кешесенә бирде. Ул аңа: „Син райком секретареннан күбрәк хезмәт хакы аласың, ник ашлык тапшыруларны үтәмисең“ ди. Аннан соң район финанс бүлеге мөдиренә: „Син дәүләт акчасын ашыйсың, ник районда финанс планын үтәмисең“ ди. Ул район җир бүлеге мөдиренә, район советының башкарма комитеты председателе урынбасарына һәм башка җитәкче работникларга да шундый тупас сорауларны бирде. Минемчә, менә мондый унтерпришебеевский методлар Өлкә Комитеты работнигы булган кешегә хас нәрсә түгел.

Өлкә Комитетының эшендә җидди кимчелекләрнең тагын берсе итеп—хатын-кызларны партия эшенә, хуҗалык эшенә һәм башка тармакларга җитәкче постларга күтәрүгә аз игтибар бирелүне әйтергә кирәк. Киләчәктә мондый кимчелекләргә юл куелмаска тиеш.

Җирле промышленность һәм аңа җитәкчелек

Татарстан Җирле Промышленность Наркомы иптәш Филимонов речендән

Җирле промышленность наркоматы буенча үткән ел планы тулаем алганда 100,3 процент үтәлде. Ләкин бу әле наркоматның барлык предприятиеләре дә яхшы эшли дигән сүз түгел. Зур предприятиеләрдән саналган гармон фабрикасы, Татполиграф, „Красный Путь“ заводы планнарын үтәмәделәр. Наркомат буенча киң куллану товарлары эшләп чыгару планы бары 91 процент кына үтәлде. Продукциянең үзенә төшү бәясен киметү планы да үтәлмәде. 1940 нчы елның январь һәм февраль айларының эш нәтиҗәләре дә шулай ук мактанырлык түгел.

Район промышленносте белән эш тагын да начаррак тора. Район промышленностен үстерү өчен зур мөмкинлекләр булуга да карамастан, наркомат җитәкчеләре бу эшкә әһәмият биреп җиткергәннәре юк. Кайбер район оешмалары, район башкарма комитетлары һәм ВКП(б) ның кайбер райкомнары район промышленностен киңәйтүне һәм аңа җитәкчелек итүне үз агымына куйганнар. Хәтта кайбер районнарда безнең тарафтан оештырылган мастерскойларны ябуга кадәр барып җиткәннәр. Бөгелмә районында яхшы җиһазландырылган мебель мастерскоен япканнар. Чаллы район башкарма комитеты, үлчәү приборлары эшләү мастерскоен сыра залына әйләндерү турында карар чыгарган. Арчада чүлмәк житештерү мастерское, Кызыл Йолдыз районында мебельләр эшләү мастерскойлары „акча юк“ дигән сылтау белән эшкә җибәрелмәгәннәр. Буа районында да шундый ук хәл. Җирле промышленностьны җәелдерүгә мондый

игтибарсыз карауларга чик куелырга тиеш.

Киң куллану товарлары эшләп чыгаруны арттыру өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Кызганычка каршы, бу әһәмиятле эшкә бездә тиешле игтибар бирелми әле. Шәһәр халкына хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен мастерскойлар җитәрлек түгел. Бу мәсьәлә белән район советлары да, шулай ук Казан шәһәр оешмалары да җитәрлек шөгыльләнмиләр.

Татарстанда җирле промышленностьны үстерү өлкәсендә зур бурычлар тора. Райкомнар һәм Өлкә Комитеты җирле промышленностька җитәкчелек итү мәсьәләсенә игтибарларын көчәйтергә тиешләр.

ХӘЗЕРЛӘҮЛӘР ЭШЕНДӘГЕ АРТТА КАЛУЧЫЛЫКНЫ БЕТЕРИК

Хәзерләүләр наркоматының Татарстан республикасы буенча уполномоченные иптәш Никишкин речендән

Дәүләт алдындагы бурычларны вактында үтәү—гаять әһәмиятле чараларның берсе. Дәүләт заданиесе буенча авыл хуҗалыгы продуктларының һәрбер килограммын дәүләткә үз вактында һәм югары сыйфатлы итеп тапшыру илебезнең экономик һәм оборона куәтен тагын да ныгытуга, барлык совет халкының культуралы тормышын тагын да күтәрүгә юнәлтелгән.

Хәзерләүләр эше Татарстанда ничек тора соң? Кызганычка каршы, һич мактанырлык түгел. Дөрес, бу өлкәдә алдынгы колхозлар да юк түгел. Мәсәлән, ашлык тапшыру буенча республикабызда меңнән артык колхоз, бәрәңге, сөт һәм башка продуктлар тапшыру буенча 2 меңнән артык колхоз үзләренең планнарын вактыннан элек үтәделәр.

Гомумән, хәзерләүләр планын үтәүдә артта калучылыкның төп сәбәбен беренчедән, бу эш буенча махсус рәвештә шөгыльләнүче работникларның үз эшләрен намус белән башкару өчен кирәгенчә көрәшмәүләре белән, икенчедән, ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Совнарком карарларының үтәлешен тикшермәү, бу эшкә урындагы партия һәм совет оешмаларының йомшак җитәкчелек итүләре белән генә аңлатырга мөмкин.

Кайбер районнарда дәүләт алдындагы бурычларны үз вактында үтәүгә игтибарсыз караш фактлары да булгалады. Мәсәлән, Кызыл Йолдыз, Беренче Май, Кукмара һәм башка шундый районнарда дәүләткә ашлык тапшыру эшен икенче чиратка калдыру, колхозчыларны тәэмин иткәннән соң гына башкаруга омтылу фактлары булды. Шулай да, ВКП(б) райкомнары һәм район башкарма комитетлары бу хурлыклы хәлгә тиешле политик бәяне биреп җиткермиләр.

Бездә авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү эше белән шөгыльләнүче оешмалар аз түгел. Тик менә алар безгә, Уполнаркомзаг работникларына тиешле булышлыкны күрсәтмиләр. Мисаль өчен Маслопромны алыйк. Андагы тәртипсезлекләр турында иптәш Акчурин тукталды инде. Эштә булган кимчелекләрне бетерү турында Совнаркомда да аз сөйләнмәде. Шуңа карамастан практик эш коры сөйләнүләрдән узганы юк. Маслопром әвәлгечә начар эшләвен әле дә булса дәвам иттерә. Техник базалар тәртипсез хәлгә китерелгәннәр, учет эшләре таркалган. Шуның аркасында эштә буталчыклар туа. Мәсәлән, Питрәч районында колхозчылардан 91 мең литр сөт алынып җитмәгән. Моны Маслопромда да, шулай ук Райуполнаркомзагта да белмиләр. Мондый фактларны Кызыл Йолдыз, Шөгер һәм Дөбъяз районнары буенча да китерергә мөмкин.

Хәзерләүләр эшенә җитәкчелек һәм игтибар тамырыннан үзгәртелергә һәм ул кискен рәвештә яхшыртылырга, бу эшне партия һәм совет оешмалары чын-чынлап үз кулларына алырга тиешләр.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ һӘМ РЕВИЗИЯ КОМИССИЯСЕНЕҢ ОТЧЕТЛАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУЛАР

Кадрлар белән эшләүне фәнни югарылыкка куярга

Татарстан Халык Комиссарлары Советы председателе иптәш Гафиятуллин реченнән

Иптәшләр! Партиянең район һәм шәһәр конференцияләре, партиянең башлангыч оешмаларында отчет-сайлау җыелышлары ВКП(б)ның XVIII нче съездының тарихи карарларының үтәлешенә киң күләмдә тикшерү билгесе астында үтте.

Партиянең Татарстан оешмасы үзенең XXI нче өлкә конференциясенә бердәм рәвештә, ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм бөек Сталин тирәсенә тагын да ныграк тупланган хәлдә килде.

Отчет чоры эчендә партиянең Татарстан оешмасы республикабызның партия, совет һәм хуҗалык тормышында шактый зур уңышларга ирешге. Ләкин, шул ук вакытта, ВКП(б) Өлкә Комитетының көндәлек эш практикасында җидди кимчелекләр дә бар. ВКП(б) Өлкә Комитетының бүлекләре партиянең район һәм шәһәр комитетларына яхшылап булышмыйлар әле.

Иптәш Сталин ВКП(б) ның XVIII нче съездында ясаган докладында кадрларны өйрәнү, аларны дөрес сайлап алу, урнаштыру һәм тәрбия итү мәсьәләсенә гаять нык игтибар бирде, кадрларны партиябезнең, хөкүмәтебезнең алтын фонды дип атады.

Кадрлар белән эшләү буенча да ВКП(б) Өлкә Комитеты күп кенә нәтиҗәләргә ирешге. Партиянең XVIII нче съездыннан соң 9 ай эчендә ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы партия, совет һәм хуҗалык оешмаларына җитәкчелек эшенә 3.620 кешене раслады.

Ләкин, иптәшләр, партиянең кайбер райкомнарында, совет һәм хуҗалык оешмалары җитәкчеләрендә кадрлар сайлап алу эшенә һаман да әле формаль карашның эшәп килүен әйтергә кирәк. ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросына раслау өчен кертелгәннәр арасыннан 131 кандидатураның расланмыйча кире кайтарылуы моны ачык күрсәтә.

Татнаркомзем һәм аның җитәкчесе иптәш Черзор кадрлар мәсьәләсе белән бөтенләй шөгылләнмиләр. Соңгы ике елда Татарстан АССР да иген уңышы мәсьәләсендә хәлнең бик начар булуы Татнаркомземны һәм аның урыннардагы органнары җитәкчеләрен бик нык борчырга, алар ныклы иген уңышы алуны тәэмин итү өчен барлык чараларны күрергә тиешләр иде. Ләкин, Татнаркомземның гамсез җитәкчелеге бу хәлгә бик тыныч күз белән карый. Татнаркомземда чынбарлыкка бер нинди анализ ясалмаган шикелле, киләчәктәге эш өчен дә яхшылап, фәнгә нигезләп төзелгән план юк.

Татнаркомзем һәм шулай ук Совхозтрест терлекчелекне үстерү эше белән бик аз шөгылләнәләр. Яш терлекләрне саклап үстерү өчен көрәш бөтенләй җитәрлек түгел. Татнаркомзем да һәм шулай ук Совхозтрест та терлекләрне тук һәм җылы кышлатуны большевикларча оештыра алмыйлар. Терлек азыгы булдыру буенча урыннардагы барлык мөмкинлекләрдән файдалануны оештырасы урында алар зарарлы настроениегә, иждивенчелек настроениесенә бирелделәр. Татнаркомземда гына түгел, мондый зарарлы настроениене яклау өлкәнең кайбер башка җитәкче работникларында да күренә.

Татнаркомземның һәм аның җитәкчелегендәге кадрларга игтибарсыз карашлары, кадрларны эшкә беркетү өчен алар тарафыннан бер нинди кирәкле оештырылмавын күрсәтә. өчен бер факт: хәзерге көндә колхоз һәм совхоз производствосы өчен агрономнар, зоотехниклар, ветврачлар, механиклар бик күп кирәк. Алар җитешми. Ә ВКП(б) Өлкә Комитеты тарафыннан соңгы тапкыр үткәрелгән тикшерү, хәзерге көндә 500 дән артык авыл хуҗалыгы белгечләренең үз белгечлекләре буенча эшләмәүләрен күрсәтте. Татнаркомзем бу белгечләрдән файдалану, аларны эшкә тарту буенча бер нинди конкрет чара күрмәде.

Кадрлар мәсьәләсе буенча йомшак эшләүче наркоматлар рәтенә шулай ук Татнаркомздравны да кертергә кирәк. Соңгы бер ел ярым эчендә медицина буенча 45 фәнни работникның Татарстаннан башка өлкәләргә күчеп китү факты бер үзе генә дә Татнаркомздравның кадрлар белән йомшак эшләвен күрсәтә ала. Татнаркомздрав штаты буенча Татарстанның барлык районнарында 825 кеше эшләргә тиеш. Фактта исә шуларның бары 38,7 проценты гына эшли.

Медицина кадрлары бездә җитәрлек бармы соң? Әлбәттә, җитәрлек бар. Шуның өстенә алар һәр вакыт хәзерләнеп тә торалар. 1939 нчы елгы чыгарылыштан Татарстан өчен 105 медицина белгече билгеләнгән иде. Хәзерге көндә шуларның тик 76 сы гына районнарда эшли. Калган 29 кешенең Татнаркомздрав хәтта кайда икәнлекләрен дә белми.

Башка наркоматлар турында берничә сүз. Менә монда Наркомместпром иптәш Филимонов чыгыш ясады. Ул кайбер предприятиеләрнең артта калулары турында, кайберләренең өзеклектә булулары турында сөйләде. Бу — кимчелекне фиксацияләүдән, күңел дәфтәренә теркәп куюдан башка нәрсә түгел. Завод өзеклектә икән, аны ул хәлдән чыгарырга кирәк. Заводка барырга, массаны һәр яктан оештырырга, анда 10—15 көн тоташтан булып һәм эшне турыдан-туры үзең оештырып заводны өзеклектән тартып чыгарырга да: менә, иптәш директор, шулай эшләргә кирәк, дип әйтергә кирәк. Большевик нарком әнә шулай эшләргә тиеш.

Иптәшләр! Татарстан партия оешмасы бердәм, ул ВКП(б) Үзәк Комитеты тирәсенә, бөек Сталин тирәсенә корычтай нык тупланган. Аның көче әнә шунда. Тәнкыйтьне һәм үз-үзеңне тәнкыйтьләүне киң җәелдереп, марксизм-ленинизм таглиматы нигезләрен үзләштерү буенча армыйталмый эшләп, партияле һәм партиясез большевикларны туплап партиянең Татарстан оешмасы ВКП(б) ның XVIII нче съезды тарафыннан, бөек Сталин тарафыннан куелган бурычларны, һич шиксез, уңышлы итеп үтәр. Моңар аның көче җитәрлек (**Кул чабулар**).

Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү эшендә борылыш ясалырга тиеш

ТАССР ның ит-сөт промышленносте наркомы иптәш Абдельманов реченнән

Партиянең Татарстан оешмасы ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм иптәш Сталин җитәкчелегендә отчет чоры эчендә зур гына уңышларга иреште. Ул үзенең XXI нче конференциясенә бердәм, Ленинчел-Сталинчыл Үзәк Комитет тирәсенә, бөек Сталин тирәсенә нык тупланган хәлдә килде.

Ләкин уңышлар белән бер рәттән, партия оешмаларының эшендә, Өлкә Комитеты эшендә, бигрәк тә авыл хуҗалыгы һәм авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү мәсьәләләре буенча күп кенә җитешсезлекләр дә бар әле. Ләкин Өлкә Комитеты иген уңышы алу планын тулысынча үтәүгә җитәкчелекне кирәгенчә тәэмин итмәде. Күпчелек райкомнарда массаны Сталинчыл югары уңыш өчен, социалистик терлекчелекне үстерү өчен көрәшкә туплау эше тиешле югарылыкта тормады. Аерым райкомнар колхозчылар арасында политик-тәрбия эшләрен йомшак оештырулар һәм аңа тиешенчә җитәкчелек итмәделәр, алдынгыларның тәҗрибәләрен урталаштыру мәсьәләләренә җидди игтибар бирмәделәр.

Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү мәсьәләсе партия оешмаларыннан аеруча җидди эш таләп итә. Дәүләткә сөт һәм ит тапшыру планнарының үтәлеше ничек тора? 1939 нчы елда дәүләткә сөт-ит тапшыру планнарының үтәлеше канәгатьләнерлек булмады.

Күп кенә авыл райкомнары хәзерләү эшендә оешмаларына тиешле булышлык күрсәтмиләр. Кайбер райкомнар, район советлары башкарма комитетлары һәм уполномоченныйлар хәзерләүләрнең бу тәренә тиешле бәя биреп җиткермиләр, планны өзүчеләргә карата килешүчәнлек күрсәтәләр. Дәүләткә ит тапшыру эше, бигрәк тә, Чүпрәле, Кама Тамагы һәм Мамадыш районнарында акырын бара. Бу районнарның партия оешмалары моннан тиешле политик нәтиҗәләрне ясамадылар. Кайбер колхозлар үз интересларын дәүләт интересларыннан өстен куярга маташалар һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәүне икенче чиратка калдыралар. Мондый хәлгә чик куярга кирәк.

Өлкә оешмаларыннан кайберләренең эш стиле турында берничә сүз. Татсовнарком республика тормышындагы барлык мәсьәләләрне вактында һәм дөрес хәл итәргә чакырылган. Ләкин Татсовнарком XVIII нче съезд тарафыннан куелган бурычларның үтәлүне тулысынча тәэмин итми әле. Күп кенә мәсьәләләрне хәл итүгә борыла алмаучылык күрсәтә, үтәлешне тикшерү эше йомшак куелган. Менә бер мисаль. Маслопром аппараты структурасының дөрес булмавын исәпкә алып, безнең наркомат бу системаны үзгәртү проекты белән Татсовнаркомга 1939 нчы елның 19 нчы ноябрендә проект керткән иде. Ләкин Совнарком бу проектны бары тик февраль аенда гына карады.

Икенче факт. Штатны һәм производство расходларын кыскарту, дәүләт средстволарына экономия ясау мәсьәләсе буенча наркомат Татсовнаркомга тәкъдим белән керде. Бу тәкъдимне тормышка ашыру нәтиҗәсендә елына 120 мең сум экономия булачак һәм предприятиеләрнең, учреждениеләрнең эшләре шактый яхшырачак. Татсовнарком бу мәсьәләгә дә ашыкмады. Без, социалистик терлекчелекне үстерүгә, авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү эшенә партия оешмаларының игтибарын көчәйтергә, бу өлкәдә XVIII нче съезд күрсәтмәләрен тулы үтәүне тәэмин итәргә тиешбез.

Югары уңыш алу—хезмәтне дөрес оештыруга бәйләнгән

ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире иптәш Саланов реченнән

Колхозларда югары иген уңышы өчен көрәшнең нәтиҗәлелеге кырчылык бригадаларында хезмәтне дөрес оештыруга бик бәйләнгән. Бригадада көчләр ни кадәр дөрес урнаштырылган булса, иясезлеккә һәм тигезләүчелеккә юл куелмаса, уңыш та шул кадәр югары була. Ләкин, киресенчә, колхозчылар арасында эш хезмәт дөрес оештырылмаса, колхозларда уңыш та түбән була.

ВКП(б) ның XVIII нче съезды үзенең резолюциясендә колхозларда хезмәт дисциплинасын тагын да ныгыту һәм колхозчылар массасы арасында тәрбия эшен көчәйтү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү, хезмәтне звенолап оештыру кирәклеген күрсәтте. XVIII нче съезд тарафыннан бирелгән бу күрсәтмә безнең Татарстан колхозларында һәм совхозларында ничек үтәлә соң? Туп-туры әйтергә кирәк: колхозларда һәм совхозларда даими звенолар оештыру эше чиктән тыш начар бара. Дөрес, ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумыннан соң райкомнар, район советларының башкарма комитетлары һәм җир органнары колхозларда звеноларны сан ягыннан үстерүдә кайбер чаралар күрделәр. Әгәр, пленум вактына республикада 1.500 звено булган булса, хәзер аларның саны 10.000 нән артты.

Ләкин бу звеноларның күбесе кәгазьдә генә саналалар. Өлкә Комитеты тарафыннан үткәрелгән тикшерү күп кенә районнарда шуны күрсәтәләр. Актаныш районында 1.013 звено, Минзәлә районында 593, Бөгелмә районында 904 звено исәпләнә, ләкин звеноларның күбесе эшләми. Наркомзем Шөгер районы колхозларында 450 звено оештырылган дип саный. Ә тикшерү бу районда 450 дән 17 генә звеноның эшләвен күрсәтте.

Кайбер райкомнарның, район советлары башкарма комитетларының җитәкчеләре район җир бүлекләреннән, МТС лардан бирелгән маглүматларның дөреслеген тикшермиләр. Характерлы факт: Әтнә район җир бүлеге мөдире Тельман исемендәге колхозда 20 даими звено эшли дип район советы башкарма комитетына маглүмат биргән. Тикшереп карагач, бу колхозда бер звено дә оештырылмаганлыгы беленгән. Ә колхоз председателе иптәш Габитов даими звеноларны оештыруда практик ярдәм сорарга мөрәҗәгать иткәч, өлкән агроном иптәш Әхмәдуллин: „Безнең тарафтан күрсәтмә бирелгән, үзегез оештырыгыз“ дип җавап биргән.

Аксубай һәм Калинин районнарында даими звенолар төзү эше бераз канәгатьләнерлек бара. Калинин районы агротехника чараларын планны үтәде, биредә социалистик ярышның оештырылуы начар түгел. Бу районда бер гектардан 240—250 пот алырга йөкләмә алган звенолар бар. Ләкин алар әле берәмләп кенә санарлык.

Даими звенолар югары иген уңышы яулап алуда куәтле этәргеч булып торалар. Шуңа күрә безгә бу звеноларны оештыру, аларны чыннан да даими итү өчен, бик нык эшләргә кирәк. Наркомземның, райзоларның, МТС ларның белгечләрен, партия һәм совет активистларын даими звенолар оештыруда колхозларга һәм совхозларга практик ярдәм күрсәтү өчен җибәрергә кирәк. Колхозга яки совхозга барып, звеноны кәгазьдә генә оештыру җитми, колхоз правлениеләренә, кешеләрне дөрес урнаштыруга, звено җитәкчеләрен сайлап алуда практик •булышлык итәргә кирәк.

Ефремовчы звеноларның эшләренә ныклы ярдәм оештырылырга тиеш. Кайбер иптәшләрдә, хәтта Наркомземның аерым белгечләрендә дә, безнең Татарстан шартларында 300—400—500 пот уңыш алып булмый дигән настроение бар. Мондый ачыктан-ачык зарарлы настроениегә каршы кискен рәвештә көрәшергә кирәк. Бездә рекордлы иген уңышы алу өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Тик ул мөмкинлекләрдән тулысынча һәм дөрес файдаланырга, ефремовчы агротехниканы киң кулланырга кирәк.

Колхозларда хезмәтне оештыруда авыл хуҗалыгы эшләрен дөрес планлаштыру зур урын тота. Бригаданың, колхозның эшен плансыз алып барып булмый. Ә безнең республикада бу эш хурлыклы рәвештә начар тора. Производство планнары 10 нчы мартка 97 генә колхозда яки колхозларның 2,5 процентында гына төзелгән. Наркомзем бу эшкә тиешенчә җитәкчелек итүне райзо мөдирләреннән, МТС директорларыннан таләп итми һәм бу гаҗәп түгел, чөнки Татнаркомзем планлаштыруда үзе дә бик күп ялгышлар җибәрә. Менә мәсәлән, 1940 нчы елгы авыл хуҗалыгы эшләрен планлаштыруны алып карыйк. ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы Татарстан республикасында туңга сөрүне тәгәлләү срогын 1 нче октябрь итеп раслады, ә Татнаркомзем районнарга бу срокны 25 нче октябрь итеп җиткергән.

Иптәш Алемасов үзенең докладында ВКП(б) райкомнары еш кына хәлләрдә район җир бүлекләре эшлисе эшне үзләре башкардылар дип күрсәтте. Мондый практика райкомнар эшендә генә түгел, бәлки Өлкә Комитетының үзендә дә булды. Чөнки Татнаркомзем районнарда булган чын хәлне белми, тегеяки бу районның хәлен күрсәтә торган маглүматлар күп вакытта ялгыш булалар. Менә шуңа күрә дә ВКП(б) Өлкә Комитеты Татнаркомземнан узып әлеге маглүматларны райкомнар аркылы, ә райкомнар үз чиратында район җир бүлекләреннән узып, турыдан-туры колхозлардан алырга тиеш булдылар.

Ләкин мондый дөрес булмаган һәм хәтта зарарлы булган практика киләчәктә кабатланмаска тиеш. Партия оешмалары җир органнарын алмаштырмаска, ә алардан конкрет эш таләп итәргә тиешләр.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ОЕШМАСЫНЫҢ XXI нче ӨЛКӘ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ КӨНДӘЛЕГЕ

13 НЧЕ МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ УТЫРЫШ

Иртәнге утырышта председательлек итүче иптәш **Гафиятуллин** конференциянең утырышын ачып, ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптеш Алемасовка сүз бирә. Иптәш **Алемасов** шушы елның 12 нче мартында СССР белән Финляндия республикасы арасында солых договоры төзелү турында белдереп, конференцияне договорның эчтәлеге белән таныштыра. Героик Кызыл Армиябезнең даны турында, партиябезнең, дәүләтебезнең эзлекле рәвештә тынычлык политикасы алып барулары турында, сугыш уты кабызучыларның — Англия, Франция һәм Америка империалистларының планнары җимерелү турында иптәш Алемасовның белдерүе конференция делегатлары тарафыннан көчле алкышлар белән каршы алына.

Иптәш **Алемасов** чыгышыннан соң, конференция ВКП(б) Өлкә Комитеты, Ревизия Комиссиясе отчетлары буенча фикер алышуларны дәвам иттерә.

Беренче сүз ВКП(б) ның Ютазы райкомы секретаре иптәш **Гафиятуллинга** бирелә. Ул үзенең чыгышында отчет чоры эчендә ВКП(б) ның Татарстан оешмасы алдынгылар хисабына шактый үскәнлекне Ютазы районы мисалендә күрсәтеп үтә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш **Динмөхәметов** үзенең речен совет органнарын Сталин Конституциясе нигезендә үзгәртеп кору бурычларына, партиянең XVIII нче съезды карарлары нигезендә җирле Советлар алдында торган конкрет бурычларга багышлый. Аннары, иптәш **Динмөхәметов** Татарстанда укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенең, авылны төзекләндерү эшенең торышына тирән анализ ясап, бу өлкәдә Татарстанның XX еллыгына яңа уңышларга ирешү бурычын куя.

Татсоюз җитәкчесе иптәш **Осинцев** ВКП(б) Өлкә Комитетының отчет докладында һәм фикер алышуларда Татсоюзга карата ясалган тәнкыйтьнең урынлы һәм дөрес икәнлеген әйтү белән бергә, кайбер районнарда потребитель кооперациясе органнарына работниклар сайлап алу эшенә бөтенләй игтибарсыз караш фактларына туктала. Югары Ослан районы кооперациядәге растраталар буенча беренче урынны алып тора. Моның сәбәбе бик ачык: бу районның райпотребсоюз, партия һәм совет органнары җитәкчеләре кооперация работникларын сайлап алуда җавапсызлык күрсәтәләр. Мондагы кооперация органнарында элек растрата ясаган кешеләрне яңадан урнаштыру система булып киткән. Шунсы гаҗәп: иптәш **Осинцев** үзенең чыгышында бик күп мәсьәләләргә тукталды, ләкин Татсоюзның эшен тамрыннан яхшырту буенча, язгы чәчүгә кооперация органнарының ничек хәзерләнүе турында бер сүз дә әйтмәде.

Иптәш **Тимерханов** (Сарман районы делегаты) МТС ларга Татнаркомземның дефиренциаль җитәкчелек итмәвен, Татсовнарком тарафыннан Сарман район үзәген төзекләндерү, аерым алганда клуб төзү мәсьәләсенә игтибарның бөтенләй булмавын кискен рәвештә тәнкыйть итә. Иптәш **Хәйруллин** (ВКП(б) ның Апас райкомы секретаре) партиянең район оешмасының төп профессия работниклары — тракторчылар, комбайнчылар хисабына акырын үскәнлеген әйтеп үтә. Аннары, иптәш **Хәйруллин** өлкә газеталары эшендә булган кайбер кимчелекләрне кискен рәвештә тәнкыйтьли.

ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Долотказин** үзенең чыгышында республиканың промышленность өлкәсендә һәм Казан тимер юлы эшендә булган зур җитешсезлекләрне ачык мисальлар белән күрсәтеп, аларны бетерү өчен Наркоместпром, Наркомпищепром, Наркомлес, Казан тимер юлы җитәкчеләренең һич тә җитәрлек көрәшмәүләрен әйтә. Һәм бу җитешсезлекләрне бетерү, промышленностьның, тимер юлның яхшы эшләвен тәэмин итү буенча конкрет тәкъдимнәр ясый.

Иптәш **Петров** (ВКП(б) ның Алабуга райкомы секретаре) район оешмасының оештыру һәм идея ягыннан үскәнлеген күрсәткән күп кенә фактлар китерә.

ВКП(б) ның Лаеш райкомы секретаре иптәш **Огольцов** отчет чоры эчендә колхозларда партиянең башлангыч оешмалары сизелерлек дәрәҗәдә үскәнлекне әйтеп, әле бу эшнең һич тә канәгатьләнерлек хәлдә булмаганлыгын күрсәтә. Аннары, ВЛКСМның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Перов** чыгып сөйләде. Ул үзенең речендә ВЛКСМ ның Татарстан оешмасы эшендә булган кайбер уңышларга тукталып, комсомолның мәктәптәге эшендәге зур җитешсезлекләргә кагыла һәм аларны бетерү кирәклеген күрсәтә. Шуның белән конференциянең иртәнге утырышы тәмам була.

13 НЧЕ МАРТТАГЫ КИЧКЕ УТЫРЫШ

Иптәш Динмөхәметов председательлек итә. ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Ревизия Комиссиясенең отчетлары буенча кичке утырышта фикер алышуларда түбәндәге иптәшләр катнаштылар:

Зиннуров (Шөгер районы „Кызыл орден“ колхозының башлангыч партоешма секретаре), Шәрафиев (Наркомфим), Максимов (Алексеевский районының „Мысль Ленина“ колхозы председателе), Киселев (Татсовнарком председателе урынбасары), Рундаев (Совет Контроле Комиссиясенең Татарстан буенча вәкиле), Сәмигуллин (Ворошилов райкомы секретаре), Тенчурин (Татгосиздат), Ананьев (Ленин райкомы секретаре), Гинзбург (Наркомздрав), Куренков (Казан тимер юлы прокуроры) һәм Мөхәметов (ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре).

Кичке утырышта партиянең XXI нче Өлкә Конференциясен Казан шәһәре пионерлары котладылар.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 12 март. (ТАСС). Гавас агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 10 нчы мартта, фронт линиясе өстендә томан һәм болыт булуга да карамастан, француз һәм немец истребительләренең көчләре тигез булган ике отряды арасында һава сугышы булган. Сугышта барлыгы 12 самолет катнашкан. Һәр ике яктан да югалтулар булмаган. Бер француз очучысы нык кына яраланган.

10 нчы мартка каршы төндә шулай ук ике якның да ерак разведка ясаулары булган. Француз самолетлары Германиягә эчкәре үтеп кергәннәр. Немец очучылары Франциянең төньяк, көнчыгыш һәм хәтта көньяк-көнчыгыш өлкәләре өстендә дә очканнар.

Нид елгасыннан көньяк-көнчыгыштә шактый каты бәрелешләр булган. Вогезы районында—артиллериядән атышу.

Бүген иртәнге белдерүдә „төнбуе әһәмиятле бер нәрсә дә булмады“ диелә.

БЕРЛИН, 12 март. (ТАСС). Германия информация бюросы хәбәр итә: „фронтта патрульләрнең хәрәкәтләре сизелде. Германия һәм Франция патрульләренең бәрелеше вактында дошман алып ташланды һәм югалтуларга дучар ителде. Фронтның Саар һәм Пфальц урманы арасындагы участкысында французлар артиллериядән сирәк-сирәк атулар алып бардылар“.

БЕРЛИН, 12 март. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе белдерә: „Көнбатыш фронтта бер нинди дә әһәмиятле вакыйгалар булмады. Германия авиациясе көнчыгыш Франция өстендә разведка очышлары ясады. Германиянең зенит артиллериясе „Потез 63“ типындагы бер француз самолетын бәреп төшерде“.

Дублинда зур забастовка

ЛОНДОН, 12 март. (ТАСС). Мәгълүм ки, моннан берничә көн элек, Дублинның 2 мең муниципаль эшчесе забастовка игълан иткән иде. 10 нчы мартта забастовкачылар тизлек белән яңадан эшкә керешү турында властьларның забастовкачыларны урыннан чыгару белән янаган боерыгын массовый митингта кире какканнар. Муниципаль эшчеләр арасында шәһәрнең янгыннан саклау командалары да бар.

Хәзер Дублинда хәлләр шул кадәр киеркенләште, монда гомуми забастовка игълан ителүе мөмкин. Килеп чыккан вакыйгалардан куркуга төшкән Де Валера хөкүмәте һәр төрле янаулардан да тартынмый. Промышленность министрлегендә Дублинның 60 мең эшчене берләштерә торган профсоюзлар советы членнары белән очрашу булды. Бу вәкилләргә, әгәр дә алар забастовкачы муниципаль эшчеләргә теләктәшлек күрсәтү йөзеннән забастовка игълан итәргә маташсалар, ул чагында „хөкүмәт тарафыннан кирәкле булган барлык чаралар күреләчәк“ дип белдерелгән.

Берничә тапкыр таләп итүгә дә карамастан, забастовкачы янгынчылар эш башлаудан кискен рәвештә баш тартканнар. Бик нык коралланган гаскәрләр шәһәрнең янгынчылык командалары биналарын алганнар. Муниципалитет хезмәткәрләре дә эшкә керешү турында властьларның боерыгын үтәүдән баш тартканнар. Забастовкачы эшчеләр штрейкбрехерларга яңадан эшкә керешүгә комачауларга омтылып киң күләмдә забастовка пикетлары куйганнар. Властьлар да полиция патрульләрен көчәйткәннәр.

Кичә Эйре хөкүмәтенең башлыгы Де Валера муниципалитет вәкилләрен кабул иткән һәм алар белән забастовкачыларга каршы көрәш чаралары турында киңәшкән. Забастовкачылар хезмәт хакын атнасына 8 шиллингка арттыруны таләп итәләр. Алар хезмәт хакын 2 шиллингка арттыру турындагы тәкъдимне кире какканнар.

АНГЛИЯ ИТАЛИЯНЕҢ КҮМЕР ТӨЯГӘН КАРАБЛАРЫН АЗАТ ИТТЕ

РИМ, 11 март. (ТАСС). Барлык газеталар Италиянең моннан элек инглизлар тарафыннан тотылган һәм Германия күмере төялгән пароходларын җибәрүләре турында хәбәр итәләр. Газеталарның язуларына караганда, күмер турындагы бәхәсләрдән Италия—Англия арасындагы экономик мөнәсәбәтләрне Англия файдасына киңрәк тикшерү һәм тәртипкә кую өчен файдаланырга маташып, әле кичә генә бу мәсьәләдә килешмәүчәнлек күрсәткән инглизлар хәзер ташлама ясауга риза булганнар. Шуның белән бергә, Италия пароходларын азат итү турында Италиянең кичәге рәсми белдерүендә Англиянең киләчәктә Германия күмерен Италиягә үткәрергә җыенмаганлыгы күрсәтелә.

ЧУНЦИНДА ЯПОН ДОКУМЕНТЛАРЫ КҮРГӘЗМӘСЕ

ЧУНЦИН, 12 март. (ТАСС). Төрле фронтларда кытайлар тарафыннан кулга төшерелгән япон документларыннан Чунцинда күргәзмә оештырылды.

Япон солдатларының һәм офицерларының көндәлекләре, шулай ук япон армиясенә приказлар гаять зур кызыксыну тудыралар. Приказларның берсендә болай диелә: „Соңгы вакытта 4 нче Кытай армиясенең штатский киемнәр кигән солдатлары партизанлык сугышы алып баралар. Алар безнең сакчылык районнарыбызда һәр вакыт күренәләр һәм тимер юлларны җимерәләр“. Приказда партизаннарга каршы рәхимсез көрәш алып барырга тәкъдим ителә.

Күргәзмәдә шулай ук кытай армиясенең пропаганда материаллары да күрсәтелгән. Хэбэй, Шаньси, Шаньдун провинцияләрендә партизаннар тарафыннан чыгарыла торган газеталар, кытай һәм япон телләрендәге листовкалар, пленга төшкән япон солдатларының кытай халкына каршы сугышны туктатырга чакырып япон солдатларына язган мөраҗәгатләре һәм башкалар куелган.

ВАН ЦЗИН-ВЕЙ ТАРАФДАРЫНА ҺӨҖҮМ ИТҮ

ШАНХАЙ, 12 март. (ТАСС). Бүген, Шанхайда Франция концессиясендә Ван Цзин-вейнең күренекле тарафдары—Лу Жень-суй һәм аның хатыны үз квартираларында авыр яраланганнар. Билгесез кытайлар Лу Жень-суйның квартирасына килеп аны һәм аның хатынын балта белән берничә җирдән яралаганнар.

ИРЕК МӘЙДАНЫНДА ЗУР МИТИНГ

Кичә кич Казан шәһәре хезмәт ияләренең СССР белән Финляндия арасында төзелгән солых договорына багышланган зур митингысы булды.

ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты секретаре Бычков һәм Казан гарнизоны вәкиле лейтенант Кузнецов иптәшләрнең речьләрен митинг гаять зур игътибар белән тыңлады. Ораторлар Советлар Союзының төньяк-көнбатыш чикләрен тәэмин иткән яңа зур җиңүне күрсәтеп үттеләр һәм Ленинград Хәрби Округының героик сугышчыларын котладылар.

Көчле „ура“ тавышлары астында митинг бөек Сталинга котлау хаты кабул итте.

— Сезнең даһи җитәкчелегегез астында,—диелә хатта,—социалистик дәүләтебез җиңү артыннан җиңүгә ирешә, ул хәзер какшамас көчкә, бөтен дөньяның коллыкка төшерелгән барлык халыкларының азатлык хәрәкәте таянычына—граниттай таянычка әйләнде, ул бу халыкларны сугыш уты кабызучыларга каршы көрәшкә рухландыра.

Сезнең якты акылыгыз, Сезнең үтә сизгерлегегез һәм үтә күрүчәнлегегез белән империалистик юлбасарларның кабахәт чыгышлары фаш ителде, Советлар Союзын сугышка кертергә аларга ирек бирелмәде.

Советлар Союзы белән Финляндия арасында солых договоры төзелү турындагы хәбәрне без тирән канәгатьләнү белән каршыладык. Бу договор куркынычлы сугыш учагын юкка чыгарды, Англия—Франция империалистларының һәм аларның агентларының мәкерле уйларын җимерде.

Кадерле Иосиф Виссарионович, Ватаныбызның халыкларына тынычлык һәм куркынычсызлык тәэмин итүче зирәк тышкы политиканы котлап, без Сезне ышандырабыз: Сезнең беренче чакыруыгыз белән без Совет җирен саклауга басарга һәм һәр төрле дошманны юк итәргә хәзер торабыз.

Яшәсен безнең Ватаныбыз!

Яшәсен социализмның барлык җиңүләрен оештыручы һәм рухландыручы туганыбыз бөек Сталин!

Митингта катнашучылар шулай ук Ленинград Хәрби Округы сугышчыларына, командирларына һәм политработникларына котлау хаты кабул иттеләр.

Митингта 60 мең кеше катнашты.

КҮП СТАНОКЧЫЛАР ҮРНӘК КҮРСӘТӘЛӘР

С. М. Киров исемендәге 4 нче номерлы ясалма каучук заводының 8 нче цехында күп станокларда эшләүгә күчү тәҗрибәсе узган елның октябрендә кулланыла башлаган иде. Хәзер цехта күп станокчылар саны 48 кешегә җитте һәм алар барсы да үз нормаларын арттырып үтиләр, машиналардан һәм эш сәгатьләреннән тулы файдалануның гүзәл үрнәкләрен күрсәтәләр.

Безнең цехта хатын-кызлар хезмәте киң кулланыла. Алдынгы хатын-кызларыбыздан Хасанова, Пенкова һәм Хаштаҗанова иптәшләр элек ирләр генә башкарган эшләрне башкаралар һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечләрен бирәләр.

Х. Гарифуллин.

Казан уку йортларында оборона ярышлары. РӘСЕМДӘ: Бауман районының 41 нче номерлы мәктәбендә (10 нчы класс) укучы, отлично атучы Всеволод Стасюк.
А. Попов (ТатТАСС фотохроникасы).

СТАЛИН ИСЕМЕНДӘГЕ СТИПЕНДИЯГӘ КАНДИДАТЛАР

Казан Дәүләт университеты студентлары һәм фәнни работниклары арасында иптәш Сталин исемендәге стипендияне алу өчен социалистик ярыш киң җәелде. Хәзерге көндә университет студентларыннан 829 кеше „отлично“ һәм „яхшы“ билгеләренә укый. Алар академик өлгерешләрен күтәрү белән бергә, җәмәгать эшләрендә дә актив катнашалар, фәнни түгәрәкләрдә эшлиләр.

Иптәш Сталин исемендәге стипендияне алуга беренче кандидатлар да күрсәтелде инде. Аларның берсе химия факультетының III нче курс студенты иптәш Гудин. Иптәш Гудин, 1937 нче елны техникумны отличнога тәмамлап чыкканнан соң, университетка кергән иде. Ул, университетта укуның беренче көннәреннән үк, отличниклар сафында бара. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга хәзерлек вактында агитатор булып эшләде.

Геология факультеты студентлары Сталин исемендәге стипендияне алуга кандидат итеп иптәш Щукинны күрсәттеләр. Иптәш Щукин университетта 4 ел буена „отлично“ билгесенә укып килә. Фәнни тикшеренү һәм җәмәгать эшендә актив катнаша.

Сталин исемендәге стипендияне алуга кандидатлар итеп отличник студентлардан Миронов, Соловьев, Савинова, Лебедев иптәшләр дә күрсәтелделәр.

Д. Иртуганов.

КОЛХОЗЧЫЛАР МУЛ УҢЫШ АЛАЛАР

(Телефон буенча)

Мамадыш районы, Алкин авыл советына караган „Игенче“ һәм „Хәсәншә“ колхозларында шушы көннәрдә иген уңышы бәйрәме үткәрелде. „Игенче“ колхозы колхозчылары һәрбер хезмәт көненә 3 килограмм 400 грамм, „Хәсәншә“ колхозы колхозчылары һәрбер хезмәт көненә 4 килограмм бөртекле ашлык бүлделәр. „Игенче“ колхозы стахановчыларыннан Гата иптәш Мостафин 331 пот, Шаһвәлиев иптәш 246 пот уңыш алдылар.

Ногманов.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумында

9 нчы мартта иптәш Динмөхәметов председательлегендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының утырышы булды. Президиум хезмәт ияләре депутатларының Алексеевский һәм Столбище район советлары башкарма комитетларында кызыл армеецларнең һәм аларның семьяләренең жалобаларын кабул итү һәм хәл итү эшенең торышы турындагы мәсьәләне карады. Президиум кызыл армеецларнең һәм аларның семьяләренең жалобаларын тикшерүгә һәм хәл итүгә югарыда күрсәтелгән башкарма комитетларның председательләре тарафыннан һич тә юл куелмаслык рәвештә игътибарсыз караш булганлыкны күрсәтте.

Бу башкарма комитетларга килә торган жалобаларны учетка алу һәм аларга контроль һич тә канәгатьләнмәслек куелган. 1940 нчы елда январьның беренче яртысында Столбище район советына килгән 24 жалобаның тик 4 се үзенең срогында каралган. Шул ук вакыт эчендә Алексеевский район советы башкарма комитетына бирелгән 15 жалобаның тик өчесе каралган. Кызыл армеецларнең жалобаларын тикшерүдә волокита башка күп кенә районнарда да бар.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы кызыл армеецларнең һәм аларның семьяләренең жалобаларын тикшерү мәсьәләсе белән шөгыльләнүне район советлары башкарма комитетлары председательләренең үзләренә тапшырды һәм моннан соң бу мәсьәләне хәл итүдә түбәндәге тәртипне урнаштырырга тәкъдим итте: авыл советлары башкарма комитетлары кызыл армеец семьяләреннән жалобалар килүне көтеп тормыйча, кызыл армеец семьяләренең материаль хәлен үз инициативалары белән тикшерергә һәм мохтаҗ булганнарга кирәкле ярдәмне күрсәтергә тиешләр.

Яңа яслеләр

Узган ел Казанда һәм районнарда балалар өчен 10 ясле төзүгә дәүләт тарафыннан 2 миллион 372 мең сум акча җибәрелгән иде. Шулардан 6 ясле төзелеп эксплоатациягә бирелде. Аларның бөтенесендә 368 койка бар.

Быел районнарда 4 яңа ясленe салып бетерү өчен 312 мең сум акча билгеләнде. Шулар өстенә Казанда төрле предприятиеләр тарафыннан 5 яңа ясле төзелә.

ӘДӘБИЯТ ТҮГӘРӘГЕ ЭШТӘ

Минзәлә районының үзәк көтепханәсе янында 1937 нче елдан бирле әдәбият түгәрәге эшләп килә. Хәзер бу түгәрәктә барлыгы 25 член бар. Алар түгәрәкнең утырышларына һәр вакыт зур кызыксыну белән йөриләр.

Түгәрәк членнары һәр ун көн саен бер тапкыр җыелып, үзләренең язган әсәрләрен тикшерәләр, шулай ук әдәбият теориясенең аерым мәсьәләләрен өйрәнәләр.

Бу түгәрәктә член булып торучы иптәшләр тарафыннан һәр ай саен „Яшь каләмнәр“ дигән әдәби журнал һәм „Культура фронтында“ дигән газета чыгарыла.

Түгәрәктә Пушкин, Лермонтов һәм татар халык шагыйре Г. Тукай, атаклы язучы Ш. Камал һәм башкалар турында әдәби лекцияләр үткәрелде.

Түгәрәк членнары *Н. Харисов. Г. Гайни.*

Совет радиосының 15 еллыгы

Совет радиосына 15 ел тулды. Бу еллар эчендә Советлар Союзында куәтле радио челтәре мәйданга килде.

Татарстанда да үсеш зур. 1930 нчы елда Татарстанда 15 радиоузел, 301 радиоточка, 120 радиоалгыч булган булса, 1940 нчы елда радиоузелларның саны 130 га, радиоточкалар—42.568 гә, радиоалгычлар—5.862 гә җитте. Күп кенә колхозларның хәзер үз радиоузеллары барлыкка килде. Быел Кият, Галактионов исемендәге һәм „Коминтерн“ совхозларында радиоузеллар корылды. Балык Бистәсе районында 500 ваттлы радиоузел төзелде.

15 еллык юбилей уңае белән 13 нче мартан 23 нче мартка кадәр бөтен Союз күләмендә радио-декада үткәрелә. Радио работниклары үзләренең иҗад отчетлары белән колхозларга һәм предприятиеләргә чыгалар. Шулай ук Татарстан Радиокомитеты солистларының иҗад отчетлары да оештырыла. Татарстанда радио оешканнан бирле эшләп, хәзер республикабызның атказанган артисткасы булу дәрәҗәсенә кадәр үскән җырчы Гөлсем Сөләйманова һәм композитор Җәүдәт Фәйзи иптәшләренең иҗад концертлары биреләчәк. Юбилей көннәрендә микрофон алдында Татарстанның атказанган артисткасы Әхметова җитәкчелегендәге җыр һәм бию ансамбленең, Казан театрлары артистларының чыгышлары булачак. Москвадан Совет композиторларының иң яхшы симфоник әсәрләре тапшырылачак. Татар телендә „Чапаев“ дигән радио пьеса куярга уйланыла. Балалар өчен берничә әдәби тапшыру биреләчәк.

Декада барышында 15 ел эчендә радионың үсеше, СССР да радио челтәре, шәһәрне һәм авылны радиолаштыру темаларына радиолекцияләр, докладлар тапшырылачак.

Р. Н.

ЯШЬ ЗНАЧКИСТЛАР

Ленин районының урта мәктәпләре янындагы ВЛКСМ оешмалары массовый оборона эшенә җитәкчелекне шактый яхшырттылар. Мәктәпләрдә оборона темаларына беседалар үткәрелә. Шуның нәтиҗәсе буларак, комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр арасында хәрби эшне өйрәнү теләге нык үсте. Мәсәлән, 37 нче номерлы мәктәптәге 40 комсомолецның барсы да Осоавиахимда член булып тора. Бу мәктәптәге Осоавиахим оешмасы (председателе иптәш Баландин) соңгы ике ай эчендә 60 кешегә үсте. Массовый оборона эшен өйрәнү буенча 10 түгәрәк эшли. Соңгы ике ай эчендә 64 кеше „Ворошиловча атучы“ һәм ПВХО значокларына нормалар тапшырды.

68 нче номерлы мәктәп янындагы Осоавиахим оешмасы (председателе иптәш Ермолаев) 138 оборона значкистлары хәзерләп чыгарды. Тагын 150 кеше нормалар тапшыруга хәзерләнә. 91 нче номерлы мәктәптә 71 комсомолец исәпләнә, шуларның 57 се массовый оборона значкистлары.

А. Овчинников.

БЕЛДЕРҮ

15 нче март, кич 6 сәгатьтә Казан Дәүләт университетының актовый залында, Париж Коммунасы көне уңае белән билгеләнгән докладчылар өчен инструктив доклад була. Тема: „Париж Коммунасы көне—МОПР көне“.

Докладчы—иптәш Абдрашитов.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ФЕРГАНӘ ТӘҖРИБӘСЕН — ЮЛЛАР ТӨЗЕЛЕШЕНӘ!

ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ ТУЛЫ ҮТӘРГӘ

Төзек һәм культуралы юлларга республикабызның мохтаҗлыгы гаять зур. Без бу елны гына да 537 километр озынлыгында яңа юллар төзергә, 880 километр юлга капиталь ремонт үткәрергә, 2.400 пагонметр күләмендә күперләр салырга тиешбез. Кыскасы, бу өлкәдә башкарыла торган эшләрнең гомуми сумасы 35 миллион сумга җитәчәк. Монда Казан—Чистай—Бөгелмә тракты аеруча мактаулы һәм әһәмиятле урын ала. Бу эшләрне үз вакытында һәм тулы башкару өчен төзелеш участкыларына 600 мең кубометрдан артык төзү материаллары ташылырга һәм бу эш нигездә язгы ташкыннар башланганчы башкарылырга тиеш. Ферганә каналы төзелеше тәҗрибәсен юллар төзелешенә чын-чынлап күчерү—алда торган бөек эшләрне үз вактында башкаруга тулы гарантия бирә.

Кызганычка каршы, Ферганә колхозчыларының бай һәм гүзәл тәҗрибәсе республикабызда үзенең тиешле урнын алып җиткергәне юк әле. Политик һәм хуҗалык яктан гаять әһәмиятле булган бу эшкә формаль караш хәзергәчә бетерелмәгән.

Билгеле булганча, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Ферганә тәҗрибәсен республикабызның юллар төзелешенә күчерү турында Столбище районының „13 лет Октября“ артеле колхозчылары инициативасына югары бәя биреп, бу гүзәл башлангычны бөтен киңлегенә җәелдерү һәм төзелеш сезонына хәзерлекне 15 нче мартка тәгәлләү бурычын куйган иде. Өлкә Комитетының бу карары байтак кына районнар тарафыннан үтәлми. Красный Бор, Әтнә, Балык Бистәсе, Октябрь, Биләр районнарында бу эш чиктән тыш начар оештырылган. Монда районның партия һәм совет оешмалары юл төзелешенә икенче дәрәҗәдәге эш дип карауларын хәзергәчә дәвам иттерәләр.

Партия һәм совет оешмалары бу гаять әһәмиятле эшне чын-чынлап үз кулларына алган районнарда эшнең торышы бөтенләй башкача. Мәсәлән, Бондюг, Ютазы, Арча, Буа, Әлмәт, Яңа Писмән районнары большевистик үрнәк күрсәтәләр. Алар төзелеш сезонына тулы хәзерлекне тәэмин иттеләр, төзү материалларын эш объектларына ташу планын вактыннан элек арттырып үтәделәр. Димәк, теләк һәм инициатива булганда, алда торган эшләрне башкару өчен бөтен мөмкинлекләр бар дигән сүз.

Ә менә Столбище, Лаеш, Алексеевский, Чистай районнарында бу инициатива күренми әле. Формаль яктан караганда бар да эшләнгән, үзара ярыш договорлары да төзелгән. Тик менә договорларның үтәлеше белән кызыксынучы кеше генә юк. Договорлар төзелде дә, онтылдылар. Чистай һәм Алексеевский районнарындагы промышленность предприятиеләре үз өсләренә алган йөкләмәләрен үтәмиләр. Монда юл төзелешенә ярдәм күрсәтү буенча ВКП(б) райкомнары янында оештырылган комиссияләр дә үз бурычларын аңлап җиткермәгәннәр. Алар эшнең барышы турында сводкалар җыю белән генә чикләнәләр.

Дөресен әйтергә кирәк, без, юл төзелеше работниклары да акырын кыймылдыйбыз әле. Район башкарма комитетлары янындагы юл бүлекләре һәм төзелеш участкылары работниклары колхозлар белән йомшак бәйләнгәннәр, практик эштә оператив җитәкчелек итмиләр.

Менә шундый кимчелекләр аркасында төзү материалларын эш объектларына ташу планы 1 нче мартка республикабыз буенча бары тик 24 процентка гына үтәлде.

Яз якынлашты. Язгы ташкыннар башлануга санаулы көннәр генә калды. Кышның уңайлы шартлары максималь рәвештә файдаланылырга, төзү материалларын ташу эше кызу темп алырга тиеш.

А. Синявский.

ТАССР Совнаркомы янындагы юллар идарәсе начальнигы.

ТАТАРСТАН АССР ФИНАНС ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ

Татарстан АССР территориясендәге барлык учреждениеләрнең, оешмаларның һәм предприятиеләренең җитәкчеләренә **белдерә:**

СССР Финанс Халык Комиссариатының 1940 нчы ел, 28 нче февральдә чыгарган 116/29 нчы номерлы боерыгы нигезендә,

учреждениеләрнең, оешмаларның һәм предприятиеләрнең штатларын теркәү өчен түбәндәге яңа сроклар билгеләнде:

а) Наркомсобес, Наркомпрос, Наркомздрав, Наркомфин, Сәнгать Эшләре Комитеты, Промкооперация һәм инвалидлар кооперациясе, центросоюз һәм банклар системасында—шушы ел 1 нче апрельгә кадәр.

б) Наркомзем, Наркомторг, Наркомюст, Прокуратура, Наркомхоз, Кинемотография эшләре комитеты, ЦУНХУ, ТАССР Осоавиахим Үзәк Советы, Татарстан Совнаркомы янындагы Юллар Идарәсе, Хәзерләү һәм Элемтә наркоматлары системасында—шушы ел 15 нче апрельгә кадәр.

в) Наркомместпром, Наркомлегпром, Наркомпищепром, Наркоммясомолпром, Наркомлес, Наркомсовхоз, Наркомтоп, Наркомречфлот, Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Урман Саклау Идарәсе, Төзү Материаллары наркоматы, Автомобиль Транспорты наркоматы һәм Юллар наркоматы системасында—шушы ел 25 нче апрельгә кадәр.

Төзү материаллары, монтаж һәм геолого-разведка оешмаларының штатларын теркәтү срогы элеккечә, үзгәрешсез кала.

Күрсәтелгән сроклар үткәннән соң Дәүләт Банкысы органнары һәм озак сроклы сумалар банкларының органнары хезмәт хакы түләү өчен кирәкле акчаны 1940 нчы елда штатны теркәтү турындагы карточканың күрсәтелүе белән генә бирәчәкләр.

Татарстан АССР Финанс Халык Комиссариаты.
475—1

„Трансэнергокадр“ ның
КАЗАН АВТОМӘКТӘБЕ
производстводан аерып һәм аермыйча укытып III нче класс шоферлар хәзерләү, шулай ук III һәм II нче класс шоферларның квалификацияләрен күтәрү курсларына шушы ел 15 нче марттан
УКУЧЫЛАР АЛА
Укучылар предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм башка оешмалардан бирелгән командировка белән алыналар.
Казан, Банк урамы, 15. 467—2—1

ДӘҮЛӘТНЕҢ
„Кызыл Шәрык“ сыра заводы
0,5 һәм 0,6 литрлы
Сыра шешәләре ала
Шешәләр оешмалардан—Тукай урамындагы 107 нче йортта, ә барлык гражданнардан—заводның Казандагы барлык сыра сату урыннарында алына. 298—3—3

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында.
15 һәм 16 нчы мартта
ИРЕК
15 ндә талоннар белән кертелми.
Талон 87. Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

Машиналар төзү заводы
җиңел һәм йөк автомобильләре
сатып ала
41—54 һәм 16—22 телефоннары буенча яисә почта адресы буенча М. Ф. Шиховка мөраҗәгать итәргә. 36 нчы почта бүлеге, почта ящиге 732. 373—5—5

Горпромторгның 11 нче магазины хәзер акчасыз расчет буенча предприятиеләргә, учреждениеләр һәм оешмаларга, тимер-калай, москатель-химик товарлар һәм һәр төрле төзү материаллары сата.
Магазинның адресы: Бауман урамы, 9/11. 385—2—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 14 нче мартта
КҮЗЛӘР
Талон 135.
17 нче мартта
Булак арты „республикасы“
Талон 136.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 14 нче мартта
ЛЕНИН
Иртәгә
МАСКАРАД
Талоннар белән кертелми.
Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы, яңа фильм ТАШЛАНДЫК
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ПРЕМЬЕРА ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ДОКТОР КАЛЮЖНЫЙ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ПРИДАНСЫЗ КЫЗ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ШӘХСИ ЭШ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ЯШӘРГӘ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 756 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 986.